Республика Татарстан
Глава Бизякинского
сельского поселения
Менделеевского
муниципального района
423648, село Бизяки,
ул. Центральная. 46

Татарстан Республикасы
Менделеев
муниципаль районы
Бәзәкә авылжирлеге
башкарма комитеты
423648, Бәзәкәавылы,
Узәк урам, 46

Тел./факс 3-47-34

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

14.11.2023 ел № 4

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Мари Тәкәше авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә,

Карар бирәм:

1. 2023 елның 25 ноябре 14.00 сәг. Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Мари Тәкәше авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану буенча гражданнар җыенын билгеләргә. Җыен уздыру урыны итеп Мари Тәкәше, Үзәк урам, 1 йортны билгеләргә

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«2024 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Бәзәкә авылы җирлегенең Мари Тәкәше авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларга тиңләштерелгәннәрдән, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, ә күп балалы гаиләләрдән 50% ка киметеп 500 сум күләмендә билгеләргә, махсус хәрби операциядә катнашучыларны түләүдән азат итәргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә сез ризамы:

1. Мари Тәкәше авылына юлларны кардан чистарту
2. Мари Тәкәше авылында вак таш сатып алу

«РИЗА» «КАРШЫ»

7. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында - www.mendeleevsk.tatar.ru «Бәзәкә авыл җирлеге» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Бәзәкә авыл җирлеге башлыгы И.И. Кәшәфетдинов